ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.11.2022 Казан ш. № 386-102/кс-2022

«Водоканал» муниципаль казна предприятиесе өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 03.12.2021 №442-121/кс-2021 карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2023 ел өчен үзгәреш кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 15 ноябрендәге 36-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә, 2023-2024 елларга җайга салынулы оешманың эчә торган суга, ташландык су агызуга озак сроклы тарифларына һәм кирәкле тулай табышына төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Водоканал» муниципаль казна предприятиесе өчен 2022-2024 елларга эчә торган суга һәм ташландык суга тарифлар билгеләү турында» 03.12.2021 №442-121/кс-2021 карарының (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 10.08.2022 №126-26/кс-2022 карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта 1.1 пунктчаның түбәндәге таблица графаларын:

| | | |
|---|---|---|
| «10.08.2022 №126-26/кс-2022 карар үз көченә кергән көннән башлап 31.12.2022 кадәр | 49,26 | 34,46» |

2022 елның 1 декабреннән көчен югалткан дип танырга;

1 пунктта 1.2 пунктчаның түбәндәге таблица графасын:

| | | |
|---|---|---|
| «10.08.2022 №126-26/кс-2022 карар үз көченә кергән көннән башлап 31.12.2022 кадәр | 41,05 | 28,72» |

2022 елның 1 декабреннән көчен югалткан дип танырга;

1 пунктта 1.1 пунктчаның түбәндәге таблица графаларын:

| | | |
|---|---|---|
| «01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 49,26 | 34,46 |
| 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 52,16 | 36,52 |
| 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 52,16 | 36,52 |
| 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 52,26 | 36,56» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 53,36 | 37,37 |
| 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 53,36 | 37,37 |
| 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 57,54 | 40,27» |

1 пунктта 1.2 пунктчаның түбәндәге таблица графаларын:

| | | |
|---|---|---|
| «01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 41,05 | 28,72 |
| 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 43,47 | 30,43 |
| 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 43,47 | 30,43 |
| 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 43,55 | 30,47» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 44,47 | 31,14 |
| 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 44,47 | 31,14 |
| 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 47,95 | 33,56» |

2. Әлеге карар белән төзәтелгән 2023 елга тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелә.

3. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев